| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>НИЖНЕШИТЦИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>422067, Республика Татарстан, Сабинский район,<br>с. Нижние Шитцы, ул. Тукая, 15<br>тел. (84362) 46-4-42 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШЫТСУ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br><br>422067, Татарстан Республикасы, Саба районы,<br>Түбән Шытсу авылы, Тукай урамы, 15<br>тел. (84362) 46-4-42 |

e-mail: shic.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

27.02.2021 — №8

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитетының 23.04.2019 ел, №21 карары белән расланган агач һәм куаклар кисүгә, тепләүгә яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның шәхси милкендәгежирләргә кермәгән яшел үсентеләр кису тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл Советының 25.02.2021 ел № 7 карарын һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча берләштерелгән коллегиясенең 04.01.2021 ел №3-ПР беркетмәсен үтәү йөзеннән, Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 23.04.2019 ел, №21 карары белән расланган агач һәм куак кисүгә, тепләүгә яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пункттагы таблицаның икенче баганасына түбәндәге эчтәлекле 2) пункт өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар-Россия ФСХ.»;

1.2. 2.8 пунктындагы таблицаның икенче баганасына түбәндәге эчтәлекле 5) пункт өстәргә::

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

1.3. 3.4.1 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Башкарма комитет секретаре электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша җавап бирү турында сорау җибәрә:

1) күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар).

2) законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорау».

**2**. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shitsi адресы буенча бастырып чыгарырга.

**3.** Әлеге кара рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгы: Б.М.Мәүлетов